СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.07.2018 с. Шеланга № 43-190

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Устав проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль Законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына, Югары Ослан муниципаль җирлегенең Шеланга авыл җирлеге Советының 29.12.2016 елның 16-69 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль җирлегенең Шеланга авыл җирлегендә Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып,

Югары Ослан муниципаль җирлеге

Шеланга авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге башлыгы тәкъдим иткән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм аның өстендә эшне тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып дәвам итәргә (1 нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставы проекты буенча килгән тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

- эшче төркем рәисе, Югары Ослан муниципаль җирлегенең Шеланга авыл җирлеге башлыгы Майоров Валерий Викторович;

- эшче төркем секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Закирова Лилия Хәлим кызы;

Эшче төркем әгъзалары:

- Сандомирова Любовь Александровна-Шеланга мәдәният йорты мөдире;

- Синичкина Любовь Сергеевна-Шеланга СБ мөдире;

– Ефимова Сәрия Агратовна-Яңа Юл СК мөдире.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставы проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга. (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставы проектын тикшерүдә гражданнарның катнашу тәртибен расларга. (3 нче кушымта).

5. ТР Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставы проекты буенча 2018 елның 15 августында 10.00 сәгатьтә Шеланга мәдәният йортында, Шеланга авылы, Октябрь урамы, 53 йорт адресы буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

6. Эшче төркемгә Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге халкының килгән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советының Законлылык һәм хокук тәртибенең социаль-мәдәни мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,

Югары Ослан муниципаль районы

Шеланга авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров